*Ришат хәзрәт Курамшин*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире.*

**Хөрмәткә лаеклы шәхесне формалаштыру процессында милли тәрбия һәм башлангыч дини белем бирү мөмкинлекләре (Татарстанның Кукмара районы мисалында)**

***(2018 елда Милли тормыш һәм дин IX Бөтенроссия татар дин әһелләре Форумындагы чыгыш)***

Әгүүзү билләәһи минәшшәйтаанирражиим. Бисмилләһиррахмәәнирраxиим. Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә мактау булсын, Аның ахыргы пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһү гәләйһи үә сәлләмгә күңелллләребез түреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен! Әссәләмү гәләйкүм үә рәхмәтүллаһи үә бәрәкәәтүһү!

Мөхтәрәм җәмәгать! Барчабызга да мәгълүм: барлык заманнарда, һәрбер җәмгыятьтә балалар тәрбиясенә бик зур игътибар бирелде. Дөрестән дә, балалар ул – һәр дәүләтнең, һәрбер халыкның, һәр гаиләнең дәвамы, киләчәге: бүгенге балалар киләчәктә шушы ил белән идарә итәчәкләр, алар халыкның, җәмгыятьнең намусын, рухи-әхлакый мирасын, мәдәниятен, милли йөзен сакларга тиешле затлар.

Үзенең ахыргы изге китабы Коръән-Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә: “Сезнең мал-байлыкларыгыз һәм балаларыгыз – дөнья тормышының бизәге, зиннәте” (“Кәһеф” сүрәсе, 46 нчы аять). Шулай да, балаларыбыз, оныкларыбыз тормышыбызның матур бизәге булсын өчен аларның күркәм кыяфәтле булып затлы киемнән йөрүләре генә җитә микән соң? Остазларыбызның вәгазьләреннән белүебезчә, кеше төп өч өлештән тора: тән, акыл һәм җан. Сабый бала бу дөньяга туугa ата-анасы аның тәнен кайгырта башлый: ашата, эчертә, юындыра, эссе-суыктан саклый... Бала үсә төшкәч, ата-ана аның акыл үсешенә дә битараф калмый: балалар бакчасына бирә, яхшы мәктәп сайларга тырыша, хәтта төрле фәннәрдән репетиторлар яллый. Әмма өченче өлеш, ягъни җан тәрбиясе мәсьәләсе игътибар үзәгеннән читтә кала. Соңыннан ярыйсы гына чибәр, матур киенгән малай яки кыз начар юлга кереп китеп, килешсез, начар гамәлләр кыла башлагач, әти-әнисенең аны “тормышыбызның бизәге” дип инде атыйсы килми. Шуңа күрәдер дә пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.с.) үзенең бер мөбарәк хәдисендә болай дигән: “Атадан балага калган иң яхшы мирас – ул күркәм тәрбия”. Ә нәрсә соң ул “күркәм тәрбия”? Нинди кеше күркәм тәрбияле булып санала? Җавап билгеле: әшәкелектән, начар гадәтләрдән

читләшергә тырышкан, күркәм әхлакый сыйфатларга ия булган кеше генә тәрбияле булып санала. Моның өчен һәр кешегә балачактан ук гөнаһ белән савапны, хәләл белән хәрамны бер-берсеннән аера белергә, нәрсә ул дөрес юл һәм нәрсә ул начар юл, аларның аермасын, нәтиҗәләрен чамаларга кирәк. Аның өчен исә һәркем балачактан дини белем алырга тиеш.

“Хүҗүрат” сүрәсенең 13 нче аятендә Аллаһ Сүбехәнәһү үә Тәгәәлә әйтә: “Әй кешеләр! Мин сезне төрле халыклар итеп яраттым – сез бер-берегезне өйрәнер өчен”. Димәк ки, Адәм балаларының җир йөзендә төрле милләтләр булып таралып яшәүләре дә – Аллаһның хикмәтле әмер-кушуы нәтиҗәседер. “Рум” сүрәсенең 22 нче аятендәге: “Сөйләм телләрегезнең төрле булуы – Аллаһның галәмәтләреннән” – дип безгә хәбәр бирелүе дә юкка түгелдер... Чыннан да, мөселманнар Җир шарының төрле почмакларында, төрле илләрдә гомер кичерә, һәр мөселман халкы Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең кагылгысыз гыйбадәт һәм әдәп-әхлак кануннары буенча яшәргә тиеш. Шул ук вакытта, югарыда китерелгән аятьләрдән мәгълүм булганча, һәр милләт үзенең милли йөзен, милли телен, милли үзенчәлекләрен, һичшиксез, сакларга тиеш. Аять мәгънәсеннән билгеле булганча, бу – Аллаһы Тәгалә безнең өстебезгә йөкләгән бурычтыр (юкса, халыклар үз үзенчәлекләрен сакламаса, аннары бер-берсен ничек өйрәнер соң?). Шулай итеп, тәрбияле кешене үстерүдә шушы ике фактор, ягъни дини гыйлем һәм милли тәрбия, бик зур әһәмияткә ия. “Хөрмәткә лаеклы шәхесне формалаштыру процессында милли тәрбия һәм башлангыч дини белем бирү мөмкинлекләре” дип исемләнгән чыгышымның актуальлеге нәкъ шуннан гыйбарәт тә.

Белүебезчә, татарларның мең елдан артык тарихы ислам дине белән бәйле. Элек-электән милләтебез яшәешенә хас булган нәрсә ул – дини һәм милли гореф-гадәтләрнең бергә үрелеп баруы. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан дөньякүләм танылган мөселман рухи үзәкләрдән ераграк урнашкан: мәгълүм булганча, заманында ислам нигездә Шәрык һәм Урта Азия җирлекләрендә киң таралган иде, ә без Европаның төньягында урнашкан халык. Шул сәбәпле дин безгә миллилекне сакларга, милли үзаңны формалаштырырга ярдәм иткән, динлелек ныгыган саен миллилек тә ныгып барган. Яшәеш барышында бу процесс үсеш кичергән һәм шуның аркада гына татарлар Россиядә генә түгел, бөтен дөньяга үзенчәлекле милләт буларак танылган.

20 нче гасырның уртасында совет җәмгыятендә дин тыелу сәбәпле, чагыштырмача кыска вакыт эчендә – берничә дистә ел дәвамында – татарлар ассимиляцияләшеп, европалашып, милли йөзләрен югалта яздылар. Аллаһның рәхмәте белән хәзерге вакытта динлелек белән миллилекнең үзара тәэсир итешү

процессы дәвам ителә. Бу нәрсәдә чагыла соң? Шушы сорауга җавап бирер өчен Татарстанның Кукмара районында яшәүче дин әһеле буларак, үзебезнең районда бу юнәлештә башкарылган кайбер эшләрне мисал итеп китерәсем килә.

Иң элек шуны билгеләп үтәргә кирәктер: бездә районның барлык мәчетләрәрендә дә вәгазьләр фәкать татар телендә генә сөйләнә. Төрле дини һәм милли чаралар, әйтик, мәүлид кичәләре, мөселман сабантуйлары һәм башкалар шулай ук татар телендә үткәрелә.

Әлбәттә, район имамнары, ислам дине нигезләре буенча дәрес бирүче мөгаллимнәр өчен **дини белем бирү** иң беренчел мәсьәлә булып тора. Шушы юнәлештә бездә нинди эшләр башкарыла соң?

1) Безнең районда 72 теркәлгән мәчет эшләп килә, һәр авылда диярлек мәчет каршында уку елы дәвамында балалар өчен дини укулар алып барыла. Аларны мәчет имамы яисә имам рөхсәте белән Кукмара мәдрәсәсен яки Казандагы “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен читтән торып тәмамлаган абыйлар һәм апалар оештыра. Кукмара мәдрәсәсе каршында яшүсмер балалар өчен якшәмбе мәктәбе эшли, анда 11 – 15 яшьлек малайлар һәм кызлар махсус төзелгән, үз эченә унлап фәнне алган Программа буенча ислам дине нигезләрен өйрәнә.

2) Шактый күп мәхәлләләрдә җәйге һәм кышкы каникуллар вакытында балалар өчен дини укулар яки көндезге лагерьлар оештырыла. Шушы лагерьларда аралашу фәкать татар телендә бара. Анда шәһәрдән, башка төбәкләрдән каникулга кайткан рус телле балалар да булгалый, алар да, шулай итеп, ике атна дәвамында вакытларын татар телле мохиттә үткәрә.

3) Һәр елны бик зурлап район күләмендәге Коръән укучылар бәйгесе үткәрелә. Әлеге конкурс балалар өчен Коръән сүрә-аятьләрен күбрәк һәм яхшырак итеп өйрәнергә этәргеч булып тора. Анда катнашкан балаларның һәммәсенә дә күчтәнәч, ягъни пакетка салынган конфит, прәннек һәм лимонад бирелә, ә призлы урын алучыларга яхшы бүләкләр тапшырыла.

4) Төрле дини чараларга әзерләнгәндә дә (әйтик, Мәүлид кичәсендә яисә Ураза яки Корбан гаетенә багышланган чараларда чыгыш ясар өчен) балалар нәрсәдер өйрәнә һәм шулай иттереп белемнәрен арттыра.

5) Әлбәттә, барлык балалар да мәчеткә, мәдрәсәгә килеп җитә алмый. Шуңа күрә үсеп килүче буынга динне, иң элек әдәп-әхлакны өйрәтер өчен урта мәктәп мөмкинлекләрен файдалану бик яхшы булыр иде. Мәгълүм булганча, берничә ел элек Россиянең мәгариф министрлыгы фәрманы нигезендә урта мәктәпләрдә

“Основы религиозных культур и светской этики” дигән дәрес мәктәп программасына кертелгән иде. Аның Нигезләмәсендә болай дип язылган: “Главная цель введения данного комплексного учебного курса - воспитание детей в школе с учётом культурных особенностей и потребностей семьи учащегося и самого ребёнка”. Шуның нигезендә илебезнең шактый күп регионнарында “Основы православия” дип исемләнгән дәрестә укучылар христиан дине нигезләрен өйрәнә. Татарстанда мондый тәҗрибә әлегә күзәтелми, ләкин киләчәктә безнең мәктәпләрдә татар балалары өчен “Ислам дине нигезләре” дип булмаса да, Әхлак дәресләрен программага кертү турында җитди уйлана башларга вакыттыр. Чыннан да, мәчет каршындагы курслар барлык татар балаларын колачлап бетерә алмый, мәктәптә исә ислам әхлагы кагыйдәләре белән танышу укучылар өчен бик файдалы булыр иде.

**Милли тәрбия** юнәлешендә башкарыла торган эш-гамәлләргә килгәндә, шуларны искә алырга мөмкин:

1) Иң элек шуны билгеләп үтәргә кирәктер: балалар катнашындагы һәрбер дини чара фәкать татар телендә уза.

2) Ураза һәм Корбан гаете көннәрендә үзара ярышу, ягъни бәйге формасында үтә торган мөселман балалары сабантуе уздырыла. Әлеге чара дин күрсәтмәләрен һәм кагыйдәләрен генә түгел, милли гореф-гадәтләрне дә күздә тотып оештырыла.

3) Мәчет-мәдрәсәгә, төрле дини чараларга килүче балаларның тышкы кыяфәте дә игътибардан читтә калмый: малайлар, гадәттә, шушы чараларга кәләпүштән, кызлар исә татар мөслимәләре үрнәгендә бәйләнгән яулыктан килә. Гомумән, мөгаллимнәр мәчет-мәдрәсә тирәсендә йөрүче балаларга татар мөселманнарына хас булганча тәртипле дә, тыйнак та, матур да, шул ук вакытта шәригатькә туры китереп киенүнең әһәмиятен һәрдаим искәртеп тора.

4) Соңгы елларда Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте татар дин галимнәре тормышы һәм эшчәнлегенә игътибар юнәлтү максатыннан һәр елны “Фәлән галим елы” дип игълан итә. Мәсәлән, 2017 нче ел Галимҗан Барудига багышланган булса, 2018 нче ел танылган татар дин әһеле, галим Шиһабеддин Мәрҗани елы дип игълан ителде. Милләтебезнең йөзек кашы, горурлыгы дип саналган мөхтәрәм галимнәребезне шулай искә алу аларны пропагандалауга һәм милли үзаңнарыбызны үстерүгә саллы өлеш кертергә мөмкинлек бирә. Шунысы бәхәссез: үсеп килүче буын милли дин галимнәрен, дан-шөһрәт казанган шәхесләрен белергә тиеш. Шул уңайдан бездә балалар өчен дә төрле чаралар, әйтик, конкурслар, викториналар үткәрелә. Без гадәттә,

шушы галимнәрнең тормышына, эшчәнлегенә багышланган сорауларны җаваплары белән бергә балаларга алдан өләшәбез, соңыннан исә бүләкләр әзерләп, Викторина үткәрәбез. Болай эшләүнең дә уңай нәтиҗәсе, һичшиксез, бар.

Милли тәрбия һәм башлангыч дини белем юнәлешендә балалар белән эшләүнең башка мөмкинлекләре турындагы мисалларны тагын да дәвам итеп булыр иде, әмма, әлбәттә, барысы да “ал да гөл”, барысы да җиңел һәм җайлы гына бара дип әйтеп булмый, эшләгәч, проблемалары да булмыйча калмый.

1) **Проблемалар** дигәндә, иң элек мәчетләрнең, дин әһелләренең финанс хәле, йомшак кына әйткәндә, тотрыксыз булуы турында әйтергә кирәктер. Бу мәсьәләгә дәүләт тарафыннан күбрәк игътибар бирелсә, дин әһелләре күпкә нәтиҗәлерәк эшләр иде дип уйлыйм. Бүгенге көндә исә күп эшләр энтузиазм нигезендә башкарыла.

2) Туган телне өйрәнү, үзләштерү мәсьәләсенә килгәндә дә соңгы елларда шундыйрак тенденция күзәтелә: дәүләт тарафыннан милли телгә игътибар никадәр кими, шул кадәр ул зәгыйфьләнә. Без бүген шундыйрак хәлгә килеп төштек ки, ата-аналар үз балаларына: “Рус телендә укысагыз гына югары уку йортына керә аласыз, рус теле белән генә яши аласыз”, – дип тукып тора... Безнең районда яшәүчеләрнең 70 проценты – татарлар, әмма үсеп килүче буынның туган телне белүләре елдан ел начарлана гына.

3) Проблемаларның тагын берсе – телевидениедә төрле яшьтәге балалар өчен татар телендәге тапшырулар һәм мультфильмнар юк диярлек. Балаларыбыз рус телендәге мультиклар карап үсә. Бу уңайдан күптән түгел оешкан “Хузур” телекомпаниясенә дә шелтә белдерәсем килә, чөнки ул үзен Татарстанда оешкан мөселман каналы дип белдерсә дә, биредә әзерләнгән программаларның күбесе (шул исәптән балаларга атап эшләгәннәре дә) рус телендә бара.

4) Милли, дини тәрбия дип сүз кузгатабыз икән, димәк, шушы юнәлештәге матбугат эшчәнлегенә дә игътибар бирмичә булмый. Бүген татар балалары өчен татар телле гәҗит-журналлар бездә бераз нәшер ителә, ләкин үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: алар балалар өчен нигәдер кызык түгел. Ләкин алар кызык булмаса да, әле ничектер чыгарыла, ә менә балаларга адресланган татар телендә булган җайлы укыла торган дини матбугат бездә бөтенләй юк.

5) Алда билгеләп үтелгәнчә, безнең районда да, Татарстанның башка районнарында да шактый күп мәчетләр каршында балалар өчен дини укулар оештырыла. Бу эш инде байтак еллар дәвамында башкарылса да, кызганычка каршы, бүгенге көнгә кадәр бездә махсус балалар өчен әзерләнгән дини

дәреслекләр әле юк. Шуңа күрә мөгаллимнәр олылар файдалана торган дәреслекләрне балаларга яраклаштырып, үзләре ничек булдыра – шулай укыта.

6) Укыту белән бәйле тагын бер мәсьәлә турында әйтеп китәсем килә. Мәчет каршындагы курсларның күбесендә балаларны укыту гарәп хәрефләрен һәм намаз уку тәртибен укытудан гына гыйбарәт. Әмма безгә бит бүген дини ликбез гына түгел, тәрбия эшен дә алып барырга кирәк. Әдәп-әхлакка игътибар бирмәгәнгә күрә балалар мәчетнең әдәбен белми, киенү мәсьәләсенә җиңел карый, олыларга хөрмәт күрсәтми. Гади генә мисал: еш кына бала мәчеткә майка һәм бик кыска шортик киеп килә, аннары олыларны артта калдырып, үзе алдагы сафка баса (шәригать буенча исә балигъ булмаган балалар алдагы саф тулмаган булса да, икенче саф булып артта басарга тиеш). Яки күрешү-исәнләшү мәсьәләсе: бездә , татар мөселманнарында, ике куллап күрешү гадәте бар, әмма кайбер ир балалар бабайларга бер кулын гына биреп күрешә. Болар әллә ни зур мәсьәлә булып тоелмаса да, шушы нәрсәләргә дә без салкын карарга тиеш түгел дип уйлыйм.

7) Һәм тагын бер мәсьәлә (ул һәрбер төбәктә мәчет каршында белем бирүче мөгаллимнәрне борчый торган проблема) – мәчеткә укырга килгән балаларның бераз укыганнан соң таралуы, укуларын ташлаулары: ягъни белем алырга дип килгән балаларны ничек туплап саклап калырга, укуларын дәвамлы, нәтиҗәле итәргә – бүген безгә бу хакта да уйланмыйча булмый. Әлбәттә, бу мәсьәләдә, бик күп нәрсә мөгаллимнән тора, ләкин кайвакытта мөгаллим үзе дә аптырап кала, чөнки бераз гына басым ясый башлый икән, укучылар дәрескә килми, артык йомшаклык күрсәтсә – бернәрсә өйрәнми, дәрескә әзерләнмичә килә. Мондый очракларда нәрсә эшләргә була? Иң элек шуны әйтәсем килә: дини белем бирүче мөгаллим беркайчан да усаллык, ачу белдереп, холыксызланырга тиеш түгел. Бу һичшиксез, балаларны укудан биздерәчәк. Балалар белән ихластан арлашырга, ешрак тормыштан алынган гыйбрәтле хикәяләр сөйләргә, күңелләренә кызыксыну, хикмәт орлыклары салырга кирәк. Сүрәләрне, догаларны ятлауга, башка материалны үзләштерүгә килгәндә, без үзебездә, мәсәлән, ятлау буенча айлык, яртыеллык һәм еллык нәтиҗәләр чыгарабыз, ягъни, мәсәлән, ай ахырында иң яхшы ятлап баручыларны барлыйбыз һәм 1 нче, 2 нче, 3 нче урыннар билгеләп, кечкенә генә бүләкләр бирәбез. Яртыеллык һәм уку елы ахырында исә бераз саллырак бүләкләр әзерлибез. Шуны күреп, башка балалар да тырышып ятлый башлый. Әлбәттә, мәчеткә, мәдрәсәгә килүче балалар сәләтләре буенча аерыла: кемдер тиз һәм яхшы ятлый, кемдер алай булдыра алмый, ләкин тырыша – мөгаллим һәр тырышкан баланы билгеләп үтәргә тиеш.

Әлбәттә, безне бүген мәчеткә укырга килгән шактый күп балаларның өйләрендә дини мохит булмавы да борчый, ягъни бик күп очракларда дин белеме ала башлаган балага ата-ана терәк була алмый. Ә бит уйлап карасаң, **милли һәм дини тәрбия эшендә** иң зур **җаваплылык** нәкъ менә ата-аналарга йөкләнә. Мөхтәрәм хәзрәтебез, Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев әйткәнчә, безгә “үз өебездә, үз гаиләләребездә татар телен дәүләт теле итәргә, ислам динен исә дәүләт дине итәргә беркем дә комачауламый”. Хөрмәткә лаеклы шәхес формалашыр өчен, кеше үз халкының асыл гореф-гадәтләрендә тәрбияләнергә тиеш. Милли үзенчәлекләрне югалту үз йөзеңне югалтуга тиң. Шушы дөньяны без Яратучыбыз Аллаһы Тәгалә аны ничек бар кылган – шулай сакларга тиеш. Мәсәлән, урманда бер төрле генә агач, болында бер төрле генә чәчәк калса, дөнья үз ямен югалтыр иде. Шулай ук җир шарында фәкать бер генә милләт, әйтик гарәпләр генә, яисә урыслар яки французлар гына калса, кешелек дөньясы бик күп нәрсә югалтыр иде. Нинди генә кешене алсак та, ул нинди дә булса милли традицияләр кысаларында яши һәм камилләшә. Бу Аллаһы Тәгалә урнаштырган канун. Бу дөньяда нинди дә булса милләттән тыш яшәп булмый. Әмма миллилек тә һичшиксез дингә, рухияткә, Аллаһы Тәгалә билгеләгән боерык-күрсәтмәләргә һәм әхлакый кагыйдәләргә нигезләнгән булырга тиеш. Дини, рухи кыйммәтләр безгә бер-беребезне хөрмәт итеп, үзебездә һәм балаларыбызда югары әхлаклы шәхескә хас булырга тиешле сыйфатларны тәрбияләүне һәм шул сыйфатларга нигезләнеп яшәүне шарт итеп куя. Шулай итеп, милли традицияләр белән сугарылган рухият безнең тормышыбызның төпле нигезе булырга тиеш. Шулай булганда гына без һәм безнең балаларыбыз “Аллаһның бәндәсе” дигән югары исемгә лаек булырбыз, бу дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирешә алырбыз.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Әссәләмү гәләйкүм үә рәхмәтүллаһи үә бәрәкәәтүһү!